РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Тезучеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 27 сентябре № 51

Түбән Кама шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 4 нче кушымтаның һәм 16 нчы кушымтаның 3 пунктларында «социаль характердагы түләүгә керә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 1 сентябрендәге «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама шәһәре бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 40 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада таблицаның беренче юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 |

3. Түбән Кама муниципаль район Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама шәһәре Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин